**Татарстан Республикасы Азнакай район**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №217-24 2023 елның "18" апреленнән

Азнакай район Советының 2019 елның 15 февралендәге 237-34 номерлы «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Конституциясе, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте**:

1. Азнакай район Советының 2019 елның 15 февралендәге 237-34 номерлы «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслау хакында» карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы (Гыйләҗева З.С.) «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәне теркәгәндә мөрәҗәгать итүче сыйфатында чыгыш ясарга, Нигезләмәне законда билгеләнгән срокларда дәүләт теркәвенә алырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин